КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 декабрь г.Казань № 1087

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 май, 289 нчы; 2018 ел, 7 февраль, 64 нче; 2018 ел, 4 июль, 548 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

33 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «33. | Татарстан АССРның 100 еллыгы оешуга багышланган «Спортлы Татарстан» республика фестивален үткәрү | 2020 ел | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан халыклары ассамблеясы (килешү буенча), Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты (килешү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары (килешү буенча)»; |

47 нче пунктны төшереп калдырырга;

Планның «1. Төп республика чаралары» дигән бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 50.1 – 50.4 нче пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «50.1. | Казан шәһәрендә Халыкара музей форумын үткәрү | 2020 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 50.2. | «Тарихи шәһәрләр лигасы» халыкара оешмасының XVII конференциясен үткәрү | 2020 ел | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 50.3. | Татарстан Республикасы Милли музеенда Татарстан АССРның 100 еллыгы оешуга багышланган экспозиция булдыру | 2019 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 50.4. | Тарихый һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау органнарының XIX еллык Бөтенроссия съездын үткәрү | 2020 ел | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты»; |

Планның «2. Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат белән тәэмин итү» дигән бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 59.1 нче пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «59.1. | «Кеше һәм вакыт» документаль циклын булдыру | 2020 год | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы»; |

68 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «68. | «Татарстан парламенты: аның лидерлары тарих көзгесендә» китабын бастырып чыгару | 2019 год | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин